ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИКЛӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

# КАРАР

№16 Биклән авылы 2019 елның 22 октябре

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Биклән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

Карар:

1. 2019 елның 2 ноябрендә 14.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең Кызыл Юл поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Кызыл Юл авыл җирлеге территориясендә 2020 елда һәр балигъ булган кешегә 500(биш йөз) сум күләмендә түләү кертергә, 1 нче һәм II төркем инвалидларына, Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм студентларга көндезге формада белем алучы, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләүне киметергә һәм әлеге категория гражданнар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләргә килешәсезме?:

- Кызыл Юл поселогы эчендәге юлларга чокырларны ямау һәм вак таш салу ;

« ӘЙЕ» «ЮК»

3. Татарстан Республикасы, Тукай районы,Кызыл Юл поселогы , Үзәк урамы адресы буенча гражданнар җыенын үткәрергә .

4. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында " авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Биклән авыл җирлеге башлыгы М. Ш. Сәхбеев